Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге башлыгы

Карар №4,

01.11.2020 ел

«Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегенең Беловка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 ст. нигезендә Карар бирәм:

1. Татарстан РеспубликасыАксубай районы Беловка авылы Полевая урамы1 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 2020 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Аксубай районы Беловка авылы Полевая урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында 2020 елның 11 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Халык җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлегендә яшәүчеләрнең исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
1) Ленин ур., Киров ур., Елга ур., Кече ур., Бакча ур.
2) Шелеби ур., Кыр ур., Яшьләр ур., Яңа ур., Яшел ур., Сөлчә ур.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш,һәр балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?

**Беловка авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**
-Беловка торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: (грунт күтәрү, грейдерлау, вак таш салу, тигезләү ,килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- авыл юлларына вак таш җәю өчен вак таш сатып алу
- Беловка авыл җирлегенең Беловка торак пункты чикләрендә юлларны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

« РИЗА» « КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Интернет челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга :http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:/ / pravo. tatarstan. ru)бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Беловка авыл җирлеге
башлыгы башлыгы И. Р. Мәхмүтов